

# Советлар Союзы геройлары-

# безнең якташлар



**Бари Габдрахман улы Габдрахманов (1912-1944)**

**Бари Габдрахман**
**улы Габдрахманов**

**1912 елның 25 маенда Кармыш авылында туган. Бөек Ватан сугышында 1941 елның октябреннән. 2 нче Украина фронтында сугышкан.**

**1944 елның 15 январендә 233 нче гвардия артиллерия полкының орудие төбәүчесе, кече сержант Бари Габдрахманов Кировоград өлкәсенең Грузское авылы янындагы бәрелештә дошманның бер танкын, ике штурм орудиесен һәм ике пулеметын сафтан чыгара. Орудие коручысы белән икәү калып, соңгы снаряд беткәнчегә кадәр ут алып бара, ә аннан соң автоматтан гитлерчыларны кыра.**

**Бу сугышта кече сержант Бари Габдрахман улы Габдрахманов авыр яралана һәм 23 нче январендә аның гомере өзелә. Кировоград шәһәрендә Мәңгелек Дан Пантеонында җирләгән.**

**Командованиенең сугышчан бурычларын үрнәк төстә башкарган, батырлык һәм каһарманлык күрсәткән өчен СССР Верховный Советы Президиумының 1944 ел 13 сентябрь Указы белән кече сержант Бари Габдрахман улы Габдрахмановка, үлгәннән соң, Советлар Союзы Герое исеме бирелә.**



**Курасанов**

**Петр Семенович**

**(1915-1984)**

# Петр Семенович
# Курасанов

**1917 елның 25 январендә Чирмешән авылында туган. 1935 елдан Казан укытучылар институтында укый, 1937 елда Беренче Май районы мәгариф бүлеге инспекторы булып эшли башлый.**

**Лейтенант Петр Курасанов Бөек Ватан сугышында 1941 елның 22 июненнән Көньяк- көнбатыш фронтта сугыша, гаубица- артиллерия полкында взвод командиры була.**

**Берлинны штурмлаганда совет гаскәрләре юлында хәрби диңгез училищесының бик зур биналарны бердәм комплексы итеп туплаган көчле каршылык очрый.**

**Майор Курасанов училищега илтә торган юлларны өйрәнеп, полкның берничә батареясын үзе туры наводкага чыгара. Көчле ут ярдәмендә биналар җимерелә, немец горнизонының күпчелеге шунда һәлак була. 4 танк, 3 штурм, 6 артиллерия орудиесе, 10 миномет, 12 пулемет, 600 солдат юкка чыгарыла. Укчы һәм танк подразделениеләре училище территориясенә бик тиз үтеп керәләр һәм бу совет гаскәрләренең Берлинга бару юлында мөһим роль уйный.**

**СССР Верховный Советы Президиумының 1945 ел 31 май Указы белән Петр Семенович Курасановка Советлар Союзы Герое исеме бирелә, Ленин ордены һәм "Алтын Йолдыз" медале тапшырыла.**



**Цаплин**
**Павел Алексеевич**
**(1906-1937)**

# Павел Алексеевич Цаплин

**1906 елның 23 декабрендә Мордва Афонькәсе авылында туган. 15 яшендә, әти-әнисе 1921-1922 еллардагы ачлыктан үлеп, ятим кала, балалар йортында тәрбияләнә.**

**1923 елда Кызыл Армия сафларына алына. 1926 елда Тулада хәрби пехота мәктәбен, 1932 елда Ленинградта бронялы танк курсларын тәмамлый, танк ротасы командиры итеп билгеләнә.**

**1936-1939 еллардагы испан халкының милли-революция сугышында катнаша. Д.Г. Павловның танк бригадасы составында Мадрид янындагы һәм Теруэль юнәлешендәге сугышларда ике тапкыр яралана. Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.**

**Арчен шәһәре янындагы атакаларның берсендә аның танкына дошман снаряды эләгә. Цаплин авыр яралана, ләкин сугышны ташлап китми. Озакламый рота яулап алган позициядә, күп кан югалтулардан капитан Цаплинның гомере өзелә.**

**Советлар Союзының оборона куәтен ныгыту буенча Хөкүмәтнең махсус заданияләрен үрнәк төстә үтәгәне һәм каһарманлык күрсәткәне өчен, СССР Үзәк Башкарма Комитетының 1937 ел 27 июнь Карары белән капитан Цаплин Павел Алексеевичка Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Ул-Татарстанның беренче Советлар Союзы Герое.**



**Россия Герое**
**Супонинский**
**Александр Анатольевич**


# Александр Анатольевич Супонинский

**1978 елның 3 апрелендә Шешминка авылында туган. 1995 елда мәктәпне тәмамлап Чистай совхоз-техникумында укый, техник-механик белгечлеге ала.**

**1998 елда армия сафларына алына, һава-десент гаскәрендә хезмәт итә. 2000 ел башыннан Чечен Республикасындагы сугышчан бәрелешләрдә катнаша.**

**2000 елның 29 февралендә өлкән сержант Супонинский 6 нчы рота составында Шатой районында 776.0м биеклегендә оборона тота. Десантчылар позициясен боевикларның күп санлы көчләре атакалый. Өлкән сержант Супонинский аягы яраланган хәлдә автоматтан бандитларны утка тотуын дәвам итә. Боевикларның соңгы ыргылышына десантчылар бары дүрт автомат белән каршы тора. Сугышның ни белән бетәсе ачыклангач, офицер кушуы буенча, Супонинский ярдан сикерә, исән калып, узенекеләр янына барып чыга.**

**Төньяк Кавказда законсыз кораллы формированияләрне юк итүдә батырлыгы өчен, Россия Президентының 2000 ел 12 март 484 санлы указы белән Супонинский Александр Анатольевичка Россия Федерациясе Герое исеме бирелде, “Алтын Йолдыз” медале тапшырылды. Хәзер ул Татарстан Эчке эшләр министрлыгында хезмәт итә, полиция өлкән лейтенанты.**



**Ларионов**
**Семен Архипович**
**(1915-1984)**

## Ларионов С.А.

**1915 елның 1 апрелендә Чирмешән авылында туган. 1933 елда механизаторлар курсын тәмамлап, тракторчы булып эшләгән. Бөек Ватан сугышында 1942 елның апреленнән. Үзәк фронтның 65 армиясе, 96 нчы укчы дивизиясе, 237 нче укчы полкында ут взводы командиры, өлкән сержант Семен Ларионов Украинаның Чернигов өлкәсе Репкин районы Радуль поселогы янында Днепрны кичкәндә зур батырлык күрсәтә. 1943 елның 16 октябрендә штурм төркеме белән Ларионов Днепрны кичә, аннан соң уңъяк ярдагы плацдармны яулап, кулга төшерәләр.**

**Командованиенең сугышчысы бурычларын батырларча үтәгәне өчен, СССР Верховный Советы Президиумының 1943 ел 30 октябрь Указы белән өлкән сержант Ларионов Семен Архипович Советлар Союзы Герое исеменә лаек була, аңа Ленин ордены һәм "Алтын Йолдыз" медале тапшырыла.**



**Конев Иван Никитич**

**(1899-1983)**

# Иван Никитич Конев

**1898 нче елның 23 декабрендә Шешминская крепость авылында туган. Кызыл армия сафларында 1918 нче елның июненнән, 1936 нчы елда М.В. Фрунзе исемендәге РККА Хәрби академиясен, 1939 нчы елда Генераль штаб академиясен тәмамлый. 1939 нчы елда Халхин-Гол елгасында Япон мелитаристларына каршы сугышларда катнаша. 1941 нче елның июленнән – хәрәкәттәге армиядә. 1941 нче елның 24 июлендә Смоленск янындагы бәрелешләрнең берсендә авыр яралана. 1941 нче елның августыннан – Мәскәү хәрби округының сигезенче һава-десант корпусы командиры.**

**1942 нче елның декабрендә корпус өченче гвардия һава-десант девизиясе буларак үзгәртелә, полковник Конев аның командиры итеп билгеләнә һәм сугышның ахырына кадәр аның белән командалык итә.**

**Дивизия белән оста командалык иткәне, немец-фашист юлбасарларына каршы көрәштә командованиянең сугышчан заданияләрен үрнәк төстә үтәгәне, батырлык һәм каһарманлык курсәткәне өчен, СССР Верховный Советы Президиумының 1944 нче ел 13 сентябрь указы белән Гвардия полковнигы Конев Иван Никитичка Советлар Союзы герое исеме бирелә. Ленин ордены һәм “Алтын йолдыз” медале тапшырыла.**